ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.01.2021 г. Заинск № 16

**«2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында"**

Дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, «2019 - 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 сентябрендәге 857 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын расларга.
2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **Э. Э. Галеев**

О.М. Артюхова
7-52-84

**Э Ч Т Ә Л Е К**

Паспорт

1. Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә агымдагы халәткә тасвирлама.

2. Программаның максатлары, бурычлары, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары.

3. Программаны финанс ресурслары белән тәэмин итүне нигезләү.

4. Программаны гамәлгә ашыру механизмы.

5. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү.

6. Программа чаралары планы.

Зәй муницаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 16 январь
16 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

# «2021-2023 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕН ҮСТЕРҮ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Муниципаль программаның исеме** | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| **Муниципаль заказчы** | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаны төп эшләүче** | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ |
| **Муниципаль программаның максаты** | Яшьләрнең социаль үсеше белән дәүләт идарә итүе, республиканың конкурентлыкка сәләтен ныгытуда аның иҗади потенциалыннан файдалану, яшь буынның тормыш сыйфатын яхшырту өчен оптималь шартларны тәэмин итү |
| **Муниципаль программаның бурычлары** | - укучы һәм студентлар яшьләренең хезмәт активлыгының нәтиҗәле модельләрен үстерү өчен шартлар тудыру, шул исәптән икенчел мәшгульлек системасы һәм студентлар хезмәт отрядлары аша, яшь буынның инновацион потенциалын һәм эшкуарлык активлыгын үстерү;<br>- яшь буынның иҗтимагый-сәяси активлыгын һәм гражданлык компетентлыгын формалаштыру;<br>- яшьләр арасында гражданлык-патриотик тәрбия, милли үзаң һәм толерантлык системасын үстерү (Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы "2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында" Указы нигезендә (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән);<br>- яшьләр иҗтимагый оешмалары, хәрәкәтләр өчен, яшьләрнең лидерлык сыйфатларын үстерү һәм яшьләр һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары тарафыннан башлап җибәрелгән социаль әһәмиятле проектларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру;<br>- сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү, аларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру;<br>- яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалауның нәтиҗәле системасын булдыру һәм гамәлгә ашыру;<br>- яшьләр арасында экстремизм һәм террорчылык идеяләре чагылышларын профилактикалау (Россия Федерациясе Президентының "2025 елга кадәр Россия Федерациясендә |

| | |
|---|---|
| | экстремизмга каршы тору стратегиясен раслау турында" 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы нигезендә);<br>- дәүләт яшьләр сәясәтен фәнни-методик, мәгълүмати һәм кадрлар белән тәэмин итү. |
| **Муниципаль программаны тормышка ашыру этаплары һәм сроклары** | 2021 – 2023 еллар. |
| **Муниципаль программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре** | Программаны финанс белән тәэмин итү Зәй муниципаль районы бюджетыннан каралган.<br><br>Зәй муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме 77 934,9 мең сум тәшкил итә.<br>Елларга бүлеп файдалану:<br>2021 елда - 26 288,3 мең сум,<br>шул исәптән чараларга 930 мең сум;<br>2022 елда – 26 288,3 мең сум.<br>шул исәптән чараларга 930 мең сум;<br>2023 елда - 25 358,3 мең сум.<br><br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына Зәй муниципаль районының җирле бюджеты проектын формалаштырганда ел саен аныкланырга тиеш. |
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2023 елга кадәр арттыру күздә тотыла:<br>- студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтендә катнашучы яшь кешеләр өлешен;<br>- талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге башкарма хакимият органнары гамәлгә ашыра торган проектларга һәм программаларга җәлеп ителгән яшь кешеләр өлешен;<br>- иҗтимагый-сәяси активлык һәм гражданлык компетентлыгы буенча чараларда катнашучы яшь кешеләр өлешен;<br>- гражданлык-патриотик юнәлештәге чараларда катнашучы яшьләрне колачлауны;<br>- талантлы яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән конкурсларда катнашучы яшьләрне колачлауны;<br>- тискәре социаль күренешләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларда катнашучы яшьләрне колачлауны;<br>- яшьләр экстремизмын профилактикалау чараларына җәлеп ителгән яшьләр саны;<br>- дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә һөнәри осталык республика конкурсында катнашучы белгечләр санын;<br>- Яшьләр көненә багышланган чараларда катнашучылар санын; |

| | |
|---|---|
| | - балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегендә катнашучы гомуми яшьләр санында яшь кешеләрнең өлешен. |
| **Программаны үтәүчеләр** | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ, «Йолдызлык» БЯЛ МБУ, “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге” МБУ |

## 1. Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге агымдагы халәткә тасвирлама

Программа Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Зәй муниципаль районының норматив-хокукый актлары нигезендә эшләнгән һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыруга һәм гамәлгә ашыруга, балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, үстерү, социаль аякка бастыру һәм үз-үзләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, яшьләр сәясәте учреждениеләренең җәлеп итүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән.

Яшьләр эшләре идарәсе яшьләр сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыруның төп координаторы булып тора, эшчәнлегенең төп юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

- яшьләр сәясәте инфраструктурасын үстерү;
- яшьләрне социаль яклау
- яшьләрне хәрби-патриотик яктан тәрбияләү;
- балаларның һәм яшүсмерләрнең девиант тәртибен профилактикалау;
- студентларның үзешчән иҗатын һәм яшь талантларны үстерү;
- яшь гаиләләргә ярдәм итү;
- талантлы яшьләрне, яшьләр инициативаларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү;
- яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең ялын һәм буш вакытын оештыру.

Зәй муниципаль районының яшьләр инфраструктурасы Яшьләр эшләре идарәсе буйсынуындагы өч учреждениедән тора: болар - «Яшьләр үзәге» МБУ, «Форпост» МБУ һәм «Йолдызлык» балалар ял лагере МБУ. Бер яктан, алар - киң спектрлы җитди оештыру потенциалы, икенче яктан, аларны тоту һәм үстерү өчен ресурслар таләп итә торган зур комплекс.

Яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлеше - яшьләрнең социаль, иҗади һәм һөнәри мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр тудыру. Эшнең төп принцибы – яшьләр өчен яшьләрдән башка берни дә эшләп булмый. Төп чакырулардан чыгып, Зәй муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыруда төп өч максатчан күрсәтмә билгеләнде:
нәтиҗәлелек һәм ихтыяҗ;
коммуникацияләрнең яңа форматы;
яшьләргә үз мөмкинлекләрен күрсәтү өчен мохит булдыру.

Бу күрсәтмәләр программаны тормышка ашыруның мөһим юнәлешләрен һәм механизмнарын билгеләделәр.

Программа чаралары Россия Федерациясе Президентының "2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәте стратегиясе турында" 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указын (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2021 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегия» 2014 елның 2 августындагы 569 номерлы карарын тормышка ашыруга, "2025 елга кадәр Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясен раслау турында" Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы бурычлары нигезендә актуальләштерелде.

Программа чаралары план белән Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы "2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында" Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 октябрендәге 1288 номерлы "Россия Федерациясе Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында" карарын, аерым алганда федераль "Социаль активлык" "Мәгариф" илкүләм проектын, "Татарстан

Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында" 2019 елның 20 июнендәге 504 номерлы карарын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре комплексында гамәлгә ашыру чаралары каралган.

Дәүләт яшьләр сәясәте үзенчәлекләреннән чыгып, тармакара өлкә буларак, яшьләр проблемаларының бөтен спектры: белем алу, эшкә урнаштыру, буш вакытны оештыру, тискәре социаль күренешләрне профилактикалау буенча ведомствоара координацияләү эше ныгыды.

Дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыру, яшьләр проблемаларын нәтиҗәле хәл итү өчен программа алымы актив кулланыла.

Дәүләт яшьләр сәясәтен алга таба үстерү өчен яшьләр даирәсендә булган проблемаларны хәл итү кирәк:

1. Яшьләр лидерларын ачыклау, тәрбияләү һәм үз-үзләрен күрсәтү системасын камилләштерү зарурлыгы.
2. Татарстан Республикасы яшьләренең әһәмиятле ориентирларын формалаштыруда гражданлык-патриотик тәрбиянең ролен көчәйтү.
3. Яшьләрнең хезмәт активлыгын күтәрү һәм аларны иҗади проектларга яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалау чарасы буларак җәлеп итү зарурлыгы.

## 2. Программаның максатлары, бурычлары, аны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары

Программаның максаты - яшьләрнең социаль үсеше белән дәүләт идарә итүе, республиканың конкурентлыкка сәләтен ныгытуда аның иҗади потенциалыннан файдалану, яшь буынның тормыш сыйфатын яхшырту өчен оптималь шартлар тәэмин итү.

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү таләп ителә:

1. Укучы һәм студент яшьләрнең хезмәт активлыгының нәтиҗәле модельләрен үстерү өчен шартлар тудыру, шул исәптән икенчел мәшгульлек системасы һәм студентлар хезмәт отрядлары аша, яшь буынның инновацион потенциалын һәм эшкуарлык активлыгын үстерү.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтендә катнашучы яшь кешеләрнең өлеше арту күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

2. Яшь буынның иҗтимагый-сәяси активлыгын һәм гражданлык компетентлыгын формалаштыру.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге иҗтимагый-сәяси активлык һәм гражданлык компетентлыгы буенча чараларда катнашучы яшь кешеләрнең өлеше арту күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

3. Яшьләр арасында гражданлык-патриотик тәрбия, милли үзаң һәм толерантлык системасын үстерү.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге граждан-патриотик юнәлешле чараларда катнашучы яшьләрне колачлый алу күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

4. Яшьләр иҗтимагый оешмалары, хәрәкәтләр өчен, яшьләрнең лидерлык сыйфатларын үстерү һәм яшьләр һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары тарафыннан башлап җибәрелгән социаль әһәмиятле проектларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр нигезендә бәяләнәчәк:

социаль әһәмиятле проектлар һәм программалар конкурсына бирелгән гаризалар саны;

талантлы яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән конкурсларда катнашучы яшьләрне колачлау;

балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегендә катнашучы яшь кешеләрнең гомуми саны арту.

5. Сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү, аларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге, талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башкарма хакимият органнары гамәлгә ашыра торган проектларга һәм программаларга җәлеп ителгән яшь кешеләрнең өлеше арту күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

6. Яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалауның нәтиҗәле системасын булдыру һәм гамәлгә ашыру.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге тискәре социаль күренешләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларда катнашучы яшьләрне колачлау күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

7. Яшьләр арасында экстремистлык һәм террорчылык идеяләре чагылышларын профилактикалау.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге яшьләр экстремизмын профилактикалау чараларына җәлеп ителгән яшь кешеләр саны күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

8. Дәүләт яшьләр сәясәтен фәнни-методик, мәгълүмати һәм кадрлар белән тәэмин итү.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр нигезендә бәяләнәчәк:

дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә әзерләнгән докладлар, аналитик, фәнни-тикшеренү, методик эшләр саны;

дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә аттестация узган белгечләр саны;

дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә һөнәри осталык республика конкурсында катнашучы белгечләр саны;

Яшьләр көненә багышланган чараларда катнашучылар саны.

Программаны гамәлгә ашыру 2020 - 2023 елларга планлаштырылган.

## 3. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслар белән тәэмин итү Зәй муниципаль районы бюджетыннан тәгаенләнгән.

Зәй муниципаль районы бюджетыннан программаны финанслауның гомуми күләме 77 934,9 мең сум тәшкил итә.

Елларга бүлеп файдалану:

2021 елда - 26 288,3 мең сум,

шул исәптән чараларга 930 мең сум;

2022 елда – 26 288,3 мең сум.

шул исәптән чараларга 930 мең сум;

2023 елда - 25 358,3 мең сум

Программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына Зәй муниципаль районының җирле бюджеты проектын формалаштырганда ел саен ачыкланырга тиеш.

## 4. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру өчен яшьләр эшләре идарәсе һәм ведомство буйсынуындагы барлык яшьләр сәясәте учреждениеләре җаваплы.

Программаны гамәлгә ашыру механизмы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны күздә тота.

Программа белән агымдагы идарә итүне Программаның координаторы - «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ гамәлгә ашыра: муниципаль программаны эшли, Программаның аерым чараларын башка башкаручылар белән килештерүне тәэмин итә; Программаның структурасын һәм Программаның аерым чараларын башка башкаручылары исемлеген төзи; Программа чараларын үтәү өчен җаваплы муниципаль заказчылар тәкъдимнәре нигезендә Программаны гамәлгә ашыру чаралары күләме һәм чыганаклары буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра; программаны гамәлгә ашыруның барышы турында еллык хисап әзерли; «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта Программаны гамәлгә ашыру барышы һәм ирешелгән нәтиҗәләр турында мәгълүмат урнаштыра; Программаның бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өчен җавап бирә.

Программаны гамәлгә ашыруда «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ буйсынуындагы муниципаль бюджет учреждениеләре катнаша, алар Программаның бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану һәм хисап документларын үз вакытында бирү өчен җаваплы.

Программаны тормышка ашыру механизмы бюджет сметаларын төзү, раслау һәм алып бару юлы белән яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәт күрсәтүче муниципаль бюджет учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүне күздә тота. Сметалар учреждение эшчәнлеген характерлаучы һәм сметаның аерылгысыз өлеше булып торучы җирле бюджет чыгымнары буенча бюджет йөкләмәләренең бюджет чыгымнары лимитлары күләменә җиткерелгән исәп-хисап күрсәткечләренә тиешле финанс елына бюджет акчаларының әзерләнгән һәм (килештерелгән) төп күрсәтмәсе нигезендә бюджет чыгымнарының ведомство структурасын алган көннән соң ун көн эчендә төзелә. Сметалар сметаларны төзү һәм алып бару дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре, хисап һәм (яки) агымдагы финанс елы өчен бюджет учреждениесе тарафыннан сметаның үтәлеше нәтиҗәләрен һәм контроль чаралар үткәрү нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе бюджет законнарын үтәү турында мәгълүматларны, шул исәптән учреждениенең бюджет исәбен һәм хисаплылыгын оештыруны эчке финанс тикшерүе нәтиҗәләре буенча учреждениенең үзенчәлекләрен исәпкә алып төзәтелә. Муниципаль казна учреждениеләре Программаның бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану һәм хисап документларын үз вакытында бирү өчен җаваплы.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы фактта ирешелгән максатчан күрсәткечләрне аларның план күрсәткечләре белән хисап елы нәтиҗәләре буенча чагыштыру принцибына нигезләнә.

Программаны гамәлгә ашыруны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота.

## 5. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм күрсәткечләре һәм яшь буынның тормыш сыйфатын күтәрүне, яшьләрне социальләштерүне һәм үз-үзләрен тормышка

ашыруны характерлаучы төп чаралар нигезендә бәяләнә.

Программаның социаль нәтиҗәлелеге түбәндәгеләргә юнәлтелгән:

- яшь буынның социаль хәле дәрәҗәсен күтәрүгә;
- яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен тотрыклы формалаштыруга;
- яшьләр арасында хокук бозу, наркотикларга бәйлелек, алкоголизм, тәмәке тарту очракларын киметүгә;
- яшьләрнең республиканың социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси һәм социаль-мәдәни үсешенә керткән өлешен арттыруга;
- яшьләрнең патриотик, сәяси һәм гражданлык активлыгын, җитлеккәнлек дәрәҗәсен күтәрүгә;
- социаль әһәмиятле программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыру белән мәшгуль яшьләр санын арттыруга;
- яшьләрнең хезмәт, эшмәкәрлек, иҗади активлыгын арттыруга;
- яшьләрнең үз-үзен оештыру, үз-үзе белән идарә итү дәрәҗәсен күтәрүгә.

Программаны гамәлгә ашыруда тышкы куркыныч булып тора:

- Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр арасында дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү өлешендә федераль законнар үзгәреше;
- тармакны үстерүне фәнни планлаштыруның катлаулы механизмы;
- кадрлар потенциалының җитәрлек булмавы.

## 6. “2021-2023 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ЯШЬЛӘР СӘЯСӘТЕН ҮСТЕРҮ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

Программа чаралары түбәндәге финанслау күләмнәре белән түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

| № п/п | Чараларның эчтәлеге | Үтәү срогы | Башкаручылар | Финанслау чыганагы | Елларга бүлеп чыгымнар суммасы (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| **1. Укучы һәм студентлар яшьләренең хезмәт активлыгының нәтиҗәле модельләрен үстерү өчен шартлар тудыру, шул исәптән икенчел мәшгульлек һәм студентлар хезмәт отрядлары системасы аша, яшь буынның инновацион потенциалын һәм эшмәкәрлек активлыгын үстерү** | | | | | | | |
| | 1.1. Студентларның хезмәт отрядлары эшчәнлегенә ярдәм | 021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ | Җирле бюджет | 30,0 | 30,0 | 0 |
| **1. Яшь буынның иҗтимагый-сәяси активлыгын һәм гражданлык компетентлыгын формалаштыру** | | | | | | | |
| | 2.1. Яшьләрне хокукый агартуга һәм аларның хокукый белеме дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү | 2021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ | Җирле бюджет | 5,0 | 5,0 | 0 |
| **3. Яшьләр арасында гражданлык-патриотик тәрбия, милли үзаң һәм толерантлык системасын үстерү** | | | | | | | |
| | 3.1. Республика граждан-патриотик, хәрби-патриотик форумнарында, слетларда, семинарларда катнашу. | 2021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының | Җирле бюджет | 5,0 | 5,0 | 0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 3.2. Россия Федерациясе хәрби частьләре белән шефлык ярдәме һәм хезмәттәшлекне оештыру<br>3.3. Яшьләрне патриотик яктан тәрбияләүдә чаралар оештыру һәм үткәрү<br>3.4. 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннары белән яшьләрнең тантаналы очрашуын, патриотик проектлар күргәзмәсе оештыру<br>3.5. Тантаналы истәлекле чаралар оештыру һәм уздыру. | | яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ, “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге” МБУ | | 25,0<br>60,0<br>5,0<br>30,0 | 25,0<br>60,0<br>5,0<br>30,0 | 0<br>0<br>0<br>0 |
| **4. Яшьләр иҗтимагый оешмалары, хәрәкәтләре өчен, яшьләрнең лидерлык сыйфатларын үстерү һәм социаль әһәмиятле проектларга, яшьләр һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары инициативасы белән чыгучыларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру** | | | | | | | |
| | 4.1. КВН уеннарын оештыру һәм үткәрү ("Мәктәп лигасы", "Эшче яшьләр лигасы")<br>4.2. Студентлар, эшләүче авыл яшьләрен активлаштыру буенча чаралар оештыру | 2021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ | Җирле бюджет | 20,0<br>95,0 | 20,0<br>95,0 | 0<br>0 |
| **5. Сәләтле балаларны һәм яшьләрне эзләү, аларга ярдәм итү, аларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру** | | | | | | | |
| | 5.1. Иҗатта, белем бирүнең төрле өлкәләрендә талантлы яшьләргә ярдәм итү | 2021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының | Җирле бюджет | 10,0 | 10,0 | 0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 5.2. Ел саен оештырыла торган "Созвездие - Йолдызлык" эстрада сәнгате ачык республика телевизион яшьләр фестиваленең район этабын үткәрү<br>5.4. Республика Яңа ел чыршысында катнашу<br>5.5. Яшьләр көненә багышланган чаралар үткәрү | | яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ | | 150,0<br><br>50,0<br><br>350,0 | 150,0<br><br>50,0<br><br>350,0 | 0<br><br>0<br><br>0 |
| **6. Яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалауның нәтиҗәле системасын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру** | | | | | | | |
| | 6.1. Яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау чаралары оештыру | 2021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ | Җирле бюджет | 80,0 | 80,0 | 0 |
| **7. Яшьләр арасында экстремизм һәм террорчылык идеяләре чагылышларын профилактикалау** | | | | | | | |
| | 7.1. Яшьләр арасында экстремизм һәм террорчылык идеяләрен профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру | 021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ, “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен | Җирле бюджет | 10,0 | 10,0 | 0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге" МБУ | | | | |
| **8. Дәүләт яшьләр сәясәтен фәнни-методик, мәгълүмати һәм кадрлар белән тәэмин итү** | | | | | | | |
| | 8.1. Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә докладлар, аналитик, фәнни-тикшеренү, методик эшләр әзерләү<br>8.2. Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү | 2021-2023 еллар | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, «Яшьләр үзәге» МБУ, «Йолдызлык» БЯЛ МБУ, "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге" МБУ | Җирле бюджет | -<br>5,0 | -<br>5,0 | -<br>0 |
| **Чаралар буенча барлыгы:** | | | | | **930,0** | **930,0** | **0** |
| **9. Яшьләр сәясәтен үстерү** | | | | | | | |
| | 9.1. Ведомство буйсынуындагы яшьләр сәясәте учреждениеләрен тоту: | 2021-2023 гг. | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ, | Җирле бюджет | **25 358,3** | **25 358,3** | **25 358,3** |
| | 9.1.1 «Яшьләр үзәге» МБУ | | | | 21 438,7 | 21 438,7 | 21 438,7 |
| | 9.1.2 «Йолдызлык» БЯЛ МБУ | | | | 2 307,7 | 2 307,7 | 2 307,7 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 9.1.3 “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге” МБУ | | «Яшьләр үзәге» МБУ, «Йолдызлык» БЯЛ МБУ, “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге” МБУ | | 1 611,9 | 1 611,9 | 1 611,9 |
| **Барысы:** | | | | | **26 288,3** | **26288,3** | **25 358,3** |